СОВЕТ ПОДГОРНО-БАЙЛАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАУАСТЫ БАЙЛАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Тауасты Балар авыл җирлегенең Мияш торак пунктында
2025 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

**15 ноябрь 2024 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Мияш торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРА:**

1.«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге Мияш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә,1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан,көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгәннәрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Мияш торак пунктында Урманлы урамындагы 1 данә янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү);
- Су чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Мияш торак пунктында су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау (эшләрне килешү буенча түләү).

3.Әлеге карарны Тауасты Байларавыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында

бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә кабул ителгән көннән алып ун көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы,
Тауасты Байлар авыл җирлеге башлыгы ______________ З.С.Гәрәева